**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 июнь № 471

г. Казань

2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник нигезләрен ныгыту һәм картлык буенча һәм инвалидлык буенча хезмәт пенсияләре алучы эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү һәм эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле социаль программаларын финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2011 ел, 10 июнь, 456 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын 2015 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы итеп билгеләргә.

2. Теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру тәртибен;

2015 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле Татарстан Республикасы социаль программасын тормышка ашырганда барлыкка килгән Татарстан Республикасының

чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидияне тоту тәртибен.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\471.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 30 июнь, 471 нче
карары белән расланды

2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге 2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник нигезләрен ныгыту һәм картлык буенча һәм инвалидлык буенча хезмәт пенсияләре алучы эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү һәм эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле социаль программаларын финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2011 ел, 10 июнь, 456 нчы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары нигезендә өлкән яшьтәге затларның дәүләт мәгълүмат ресурсларыннан файдалана алуын тәэмин итү максатларында эшләнгән һәм 2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру тәртибен билгели.

2. 2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны Татарстан Республикасы территориясендә оештыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы була (алга таба – Вәкаләтле орган).

3. Әлеге Тәртип нигезендә, алган пенсияләренең төренә бәйсез рәвештә, Татарстан Республикасында яшәүче, 55 яше тулган хатын-кыз һәм 60 яше тулган ир-ат эшләмәүче пенсионерлар түләүсез нигездә компьютер белеменә укырга хокуклы.

4. Эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту программасы түбәндәге темаларны өйрәнүне күздә тотарга тиеш:

персональ компьютерлар турында белешмәләр;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, электрон почта һәм тавышлы аралашу чаралары белән эшләү турында белешмәләр;

WINDOWS операцион системасында эшләүнең төп принциплары;

Microsoft Word текст редакторын файдалануның төп принциплары;

мәгълүмат киоскларыннан, түләү терминалларыннан файдалану, электрон рәвештә дәүләт хезмәтләрен алу мөмкинлекләре турында белешмәләр.

5. Компьютер белеменә укыту Вәкаләтле орган ведомствосындагы учреждение (алга таба – Учреждение) дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу тармагында контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт контракты (алга таба – Дәүләт контракты) төзегән белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган мәгариф оешмасы (алга таба –Мәгариф оешмасы) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Учреждениегә 2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру вазыйфалары Вәкаләтле орган тарафыннан йөкләнә.

6. Эшләмәүче пенсионерның (алга таба – Гариза бирүче) Вәкаләтле орган раслаган форма буенча кәгазьдә яки электрон рәвештә Мәгариф оешмасына тапшырылган шәхси гаризасы компьютер белеменә укытуга кабул итү өчен нигез булып тора.

7. Гаризага түбәндәге документлары теркәлә: Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан пенсия алу фактын раслаган белешмә, паспорт күчермәсе. Булганда, гаризага пенсия таныклыгы күчермәсе, хезмәт кенәгәсе күчермәсе теркәлә.

8. Укырга хокукы булган эшләмәүче пенсионерның укыр өчен башка җирлеккә баруына һәм уку чорында башка җирлектә яшәвенә тотылган акчаны түләү яки чыгымнарын компенсацияләү Гариза бирүченең шәхси акчасы исәбеннән башкарыла.

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасының «Өлкән яшьтәге гражданнарның яшәү сыйфатын күтәрү» ярдәмче программасы кысаларында гамәлгә ашырылучы 2015 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру буенча чараларны финанслау гамәлгә ашырыла:

эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле Россия Федерациясе субъектларының социаль программаларын тормышка ашырганда барлыкка килгән Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр исәбеннән;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән.

10. Мәгариф оешмасы эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту буенча хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт контракты нигезендә:

Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларга компьютер белеменә укытуга хокуклары турында мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыра;

эшләмәүче пенсионерлардан компьютер белеменә укытуга гаризалар кабул итүне һәм аларны кергән көнендә теркәүне гамәлгә ашыра;

компьютер белеменә укыту буенча хезмәт алырга хокуклы эшләмәүче пенсионерлар исемлеген һәм алар  арасыннан уку төркемнәре төзи;

Гариза бирүченең гаризасы теркәлгәннән соң биш эш көне эчендә белем бирү хезмәтен күрсәтү һәм уку төркемен төзү өчен аны гражданнар исемлегенә кертү турында яки белем бирү хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә;

укулар башланганчы ун эш көненнән дә моңга калмыйча, Гариза бирүчегә аны уку төркеменә кертү турында һәм укыту үткәрү вакыты һәм урыны турында хәбәр итә;

дәүләт контрактында күрсәтелгән мәгариф программасы нигезендә укыту үткәрә;

курслар тәмамланганнан соң, мәгариф программасында билгеләнгән күләмдә укуны уңышлы тәмамлаган шартларда эшләмәүче пенсионерга укыту үтү турында билгеләнгән үрнәктәге документны бирә;

Учреждениегә эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту буенча хезмәтләр күрсәтү турында дәүләт контрактында билгеләнгән тәртиптә, рәвешләрдә һәм вакытларды уку үткән һәм уку үтү турында билгеләнгән үрнәктәге документлар алган Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерлар саны турында мәгълүмат (белешмәләр) тапшыра. Бу чакта 2015 елның декабренә мәгълүмат (белешмәләр) Учреждениегә 2015 елның 22 декабреннән дә соңга калмый тапшырыла.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 30 июнь, 471 нче
карары белән расланды

2015 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле Татарстан Республикасы социаль программасын тормышка ашырганда барлыкка килгән Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидияне тоту
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге 2015 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле Татарстан Республикасы социаль программасын тормышка ашырганда барлыкка килгән Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидияне тоту тәртибе (алга таба – Тәртип)

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник нигезләрен ныгыту һәм картлык буенча һәм инвалидлык буенча хезмәт пенсияләре алучы эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү һәм эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле социаль программаларын финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2011 ел, 10 июнь, 456 нчы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары нигезендә Россия Федерациясе Пенсия фонды һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасын нәтиҗәле һәм максатлы файдалану максатларында эшләнгән һәм

2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле Татарстан Республикасының социаль программасын тормышка ашырганда барлыкка килгән Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне (алга таба – Субсидия) тоту тәртибен билгели.

2. Субсидия Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ачылган бердәм счетка күчә.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылыктан Субсидия килү турында мәгълүмат алганнан соң, өч эш көне эчендә Казначылыкка 2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә

укытуны оештыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы вәкаләтле органы булып торган Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Вәкаләтле орган) финанслауның чик күләмнәренә җиткерүгә чыгым исемлеген тапшыра.

4. Вәкаләтле орган үз счетына Субсидия килгәннән соң, биш эш көне эчендә Казначылыкка Вәкаләтле орган тарафыннан 2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру вәкаләтләре йөкләнгән, Вәкаләтле орган ведомствосындагы учреждениегә (алга таба – Учреждение) финанслауның чик күләмнәренә җиткерүгә чыгым исемлеген тапшыра.

5. Акча киләчәктә Учреждение белән Мәгариф оешмасы арасында дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу тармагында контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән дәүләт контракты (алга таба дәүләт контракты) нигезендә Мәгариф оешмасы күрсәткән хезмәтләргә түләү өчен Вәкаләтле орган тарафыннан Учреждениенең Казначылыкта ачылган шәхси счетына күчерелә.

6. Дәүләт контракты кысаларында, аны тормышка ашыру белән бәйле барлык чыгымнарны да Мәгариф оешмасы тота.

7. Учреждение ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 10 көненә кадәр, Вәкаләтле орган билгеләгән формалар буенча һәм вакытларда Вәкаләтле органга эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыруга Субсидия исәбеннән чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

8. Вәкаләтле орган ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 15 көненә кадәр, Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Пенсия фонды билгеләгән тәртиптә һәм формалар буенча, социаль программаны финанслашу буенча йөкләмәләрнең Татарстан Республикасы тарафыннан үтәлүен раслаган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап һәм финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Субсидия торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

9. Вәкаләтле орган һәм Учреждение тапшырылган хисап белешмәләренең дөреслеге һәм 2015 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле чыгымнарны финанслашу тәртибендә бирелгән Субсидияне һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасын нәтиҗәле һәм максатлы файдаланган өчен законнар нигезендә җавап тоталар

10. Чираттагы финанс елына үзләштерелмәгән Субсидия һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда тиешенчә Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетына һәм Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

11. Субсидияне һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасын максатлы файдалануны тикшерүдә тотуны законнар нигезендә Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы башкара.

12. Учреждениегә бирелгән Субсидия һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы максатлы файдаланылмаган акча өлешендә Вәкаләтле органның тиешле

таләбен алган көннән соң ун көн эчендә аның Казначылыктагы шәхси счетына кире кайтарылырга тиеш.

Учреждение акчаны кире кайтару өчен билгеләнгән вакытны бозганда, Вәкаләтле орган әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән вакыт узган көннән соң биш көн эчендә күрсәтелгән акчаны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча чаралар күрә.

13. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән акчаны кайтарудан үзенең Казначылыктагы шәхси счетына кергән акчаны күрсәтелгән акча кергән мизгелдән соң ике эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылыктагы шәхси счетына күчерүне тәэмин итә.

14. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы өч эш көне эчендә Субсидияне Россия Федерациясе Пенсия фондына кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

---